**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода, ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе, Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.04.2016 Балык Бистәсе штп. № 49пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 19 декабрендәге 215 П номерлы карары белән расланган «2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 6.1 өлеше, «Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы, «Экстремистлык эшчәнлегенә каршы тору турында " 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы һәм Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2013 елның 26 апрелендә (№ Пр-1069) расланган 2013-2018 елларда Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы торуның комплекслы планын үтәү буенча Милли террорчылыкка каршы комитет тәкъдимнәрен исәпкә алып, КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 19 декабрендәге 215 пи номерлы карары белән расланган «2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

"2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау" муниципаль программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслауны» таблица кушымтасында түбәндәге эчтәлекле 4 бүлек өстәргә:

| «4. Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2013 елның 26 апрелендә (№Пр-1069) расланган 2013-2018 елларга Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы торуның комплекслы планы чаралары | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1.Терроризм идеологиясе йогынтысына дучар ителгән яки инде эләккән затларга (яшьләр; дини, нигездә ислам, чит илдә белем алган затлар; террорчылык (экстремистлык) эшчәнлеге өчен җәза алган җинаятьчеләр, яшерен банда әгъзаларының туганнары) адреслы профилактик йогынты ясау буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә даими эшләүче квалификацияле белгечләр (коллективлар) сайлап алуны оештырырга. | МБ,ОМПСиТ, РФ ЭЭМ бүлеге (килешү буенча), Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты гомуми бүлеге начальнигы урынбасары (мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы буенча) | 2016– 2017 еллар | | | | | | - | - | - |
| 4.2.Террорчылыкка каршы эчтәлекле мәгълүматны, шул исәптән видеороликларны, социаль челтәрләрдә һәм Интернет челтәренең район мәгълүмат ресурсларында блогларда әзерләүне һәм урнаштыруны тәэмин итәргә | МБ,ОМПСиТ, ОСКС, РФ ЭЭМ бүлеге (килешү буенча), Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты гомуми бүлеге начальнигы урынбасары (мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы буенча) | 2016– 2017 еллар | | | | | | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.3.Кинопрокат системасын терроризмга һәм экстремизмга каршы юнәлештәге документаль һәм нәфис фильмнар (шул исәптән видеофильмнар) таратуда кулланырга | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Киноучреждение» МБУ, ОСКС | 2016– 2017 еллар | | | | | | | | |
| 4.4.Милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән мәдәни-агарту чараларын оештыру һәм үткәрү (фестивальләр, спектакльләр) | («Авылофыклары») «Сельские горизонты» газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2016– 2017 еллар | | | | | | | | |
| 4.5.Даими рәвештә кинофильмнар күрсәтү, халык иҗаты коллективлары чыгышларын оештыру, спектакльләр күрсәтү, күргәзмәләр, түгәрәк өстәлләр, семинарлар үткәрү, «терроризмга каршы торуның мөһим факты буларак халыкара хезмәттәшлекне ныгыту»темасына багышланган кинофильмнар күрсәтү, семинарлар оештыру. | ОСКС, МБ | 2016– 2017 еллар | | | | | | | | |
| 4.6.Яшьләргә рухи һәм патриотик тәрбия бирүгә юнәлдерелгән халык иҗаты өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү | ОСКС, ОМПСиТ | 2016– 2017 еллар | | | | | | | | |
| 4.7.Терроризм идеологиясенең таралуын кисәтү максатларында, гражданнар күпләп була торган урыннарда урнаштырылган тышкы реклама чараларын һәм җайланмаларны мәгълүмати-пропаганда йогынтысы өчен | МР БК, АТК (по согласованию), ФГКУ «128-ПЧ» (килешү буенча), РФ ЭЭМ бүлеге (килешү буенча), җирлек башлыклары | 2016– 2017 еллар | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| куллануны тәэмин итәргә | (килешү буенча), | | | | | | | | | |
| 4.8.Терроризмга каршы тору өлкәсендә җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү өчен социологик тикшеренүләр үткәрүне оештырырга | МБ, РФ ЭЭМ бүлеге (килешү буенча), | 2016– 2017 еллар | | | | | | | | |
| 4.9.Патриотик рухта һәм физик яктан алга киткән яшь буынны тәрбияләүгә юнәлдерелгән, тормышта уңышының нигезе һәм терроризм һәм экстремизмны профилактикалауның мөһим алшарты буларак, шәхси иҗади хезмәткә юнәлдерелгән чараларны күздә тоткан чаралар күздә тоткан планнар һәм программалар эшләү (төзәтмәләр кертү) | ОО, ОМПСиТ, ОСКС, («Авылофыкклары») «Сельские горизонты» газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2016– 2017 еллар | | | | | | | | |
| 4.10.Яшьләргә гражданлык-патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү өлкәсендә эш алып баручы яшьләр берләшмәләре эшчәнлеген мониторинглауны тормышка ашыру | ОМПСиТ, ОСКС, РФ ЭЭМ бүлеге (килешү буенча), | 2016– 2017 еллар | | | | | | | | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин